ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«15 » сентябрь 2021 ел № 125-р

Әгерҗе муниципаль районында «Татарстан кроссы - 2021» массакүләм ярышлары үткәрү турында

«Спорт-яшәү нормасы» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 24 ноябрендәге 2390-р номерлы «Төбәкара һәм халыкара физкультура чараларының һәм спорт чараларының бердәм календарь планына, шулай ук Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең физкультура чаралары планына мәҗбүри кертелергә тиешле рәсми физкультура чаралары исемлеген раслау турында» күрсәтмәсен үтәү өчен, халыкны физик культура белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү, массакүләм физкультура-спорт эшен оештыру рәвешләрен камилләштерү, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау максатларында:

1. 2021 елның 18 сентябрендә Татарстан Республикасы, Әгерҗе ш., Ометов ур., адресы буенча «Татарстан кроссы - 2021» массакүләм ярышларын оештырырга һәм уздырырга.

2. Кушымта итеп бирелгән түбәндәгеләрне расларга:

«Татарстан кроссы - 2021» массакүләм ярышларын үткәрү турында нигезләмә;

«Татарстан кроссы - 2021» массакүләм ярышларын уздыру өчен судьялар составы;

«Татарстан кроссы - 2021» массакүләм ярышларын үткәрү турында чыгымнарның сметасы.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «СОК Олимп» муниципаль бюджет учреждениесенә массакүләм ярышлар уздыру урынын әзерләүне оештырырга, чишенү урыннарын, «Татарстан кроссы - 2021» массакүләм ярышларда катнашучыларны теркәү өчен урын бирергә.

4. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсенә» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф оешмаларының «Татарстан кроссы - 2021» массакүләм ярышларда катнашуы турында хәбәр итәргә.

5. Татарстан Республикасының «Әгерҗе үзәк район хастаханәсе» ДАССУга «Татарстан кроссы - 2021» массакүләм ярышларны медицина ярдәме белән тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе районы буенча Россия ЭЭМ бүлегенә «Татарстан кроссы - 2021» массакүләм ярышлар вакытында җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

7. Әгерҗе районының «Татмедиа» ААҖ филиалы «Әгерҗе хәбәрләре» газетасы, «Әгерҗе радиосы» җирле радиотапшырулар редакцияләренә массакүләм мәгълүмат чараларында массакүләм ярышлар уздыру турында, аның барышы һәм нәтиҗәләре турында яктырту оештырырга тәкъдим итәргә.

8. Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының спорт һәм туризм эшләре бүлеге башлыгына Алабуга, Әгерҗе, Менделеевск районнарында Татарстан Республикасы буенча кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте идарәсенә Россия Федерациясе Спорт министрлыгы һәм Россия Федерациясенең баш дәүләт санитар табибы тарафыннан 2020 елның 31 июлендә расланган COVID-19 таралу куркынычын саклап калу шартларында Россия Федерациясе территориясендә рәсми физкультура һәм спорт чараларын оештыру һәм уздыру Регламенты нигезендә планлаштырылган спорт чарасын уздыру турында хәбәр итәргә.

9. Әлеге күрсәтмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы (https://agryz.tatarstan.ru) составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

10. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетынын
15.09.2021 № 125-р
күрсәтмәсе белән расланган

**«Татарстан кроссы - 2021» массакүләм ярышларын үткәрү турында нигезләмә**

## 1.МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

1.1. Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау һәм халыкны физик культура һәм спорт белән актив шөгыльләнүгә җәлеп итү.

1.2. Массакүләм спортны үстерү һәм йөгерүне популярлаштыру.

1.3 Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының ин көчле җиңел атлетларын ачыклау.

## 2. ҮТКӘРҮ УРЫНЫ ҺӘМ ВАКЫТЫ

2.1. Җиңел атлетика йөгереше 2021 елның 18 сентябрендә Әгерҗе шәһәре, Ометов урамы адресы буенча уздырыла.

2.2. Теркәлү 09.30 дан 10.40 сәгатькә кадәр 2021 елның 18 сентябрендә МБУ «СОК Олимп»та уза.

2.3. 10.40 - 10.55 ярышларны ачу

2.4. Беренче старт 2021 елның 18 сентябрендә 11.00 сәгатьтә бирелә.

## 3. "ТАТАРСТАН КРОССЫ-2021" ҮТКӘРҮ БЕЛӘН ҖИТӘКЧЕЛЕК ИТҮ

3.1. Гомуми җитәкчелек Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының спорт һәм туризм эшләре бүлеге һәм МБУ «Спорт мәктәбе» тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.2. Җиңел атлетика йөгерешен турыдан-туры уздыру МБУ «Спорт мәктәбе»нә һәм баш судьялар коллегиясенә йөкләнә.

## 4. РЕГЛАМЕНТ

11. 00 VIP (оешма, учреждение җитәкчеләре) 500 метр дистанциягә йөгерү (ир-атлар һәм хатын-кызлар)

11.50 сәг. старт I - 2012-2013 елгылар 500 метр дистанциягә йөгерү (1 кече түгәрәк)

11.30 сәг. старт II – 2010-2011 елгылар 500 метр дистанциягә йөгерү (1 кече түгәрәк)

11.45 сәг. старт III – 2008-2009 елгылар 1300 метр дистанциягә йөгерү (1 зур түгәрәк)

12.10 сәг. старт IV  1300 метр дистанциягә йөгерү (1 зур түгәрәк)
– 2006-2007 елгылар
- 50 яшь һәм өлкәнрәкләр

12.30 сәг. старт V – 2004-2005 елгылар 2600 метр дистанциягә йөгерү (2 зур түгәрәк)

12.50 сәг. барлык теләүчеләр өчен старт - 2600 метр дистанциягә йөгерү (2 зур түгәрәк):
- 18 -29 яшь,
- 30-39 яшь,
- 40-49 яшь.

## 5. ҖИҢЕЛ АТЛЕТИКА УЗЫШЫНДА КАТНАШУЧЫЛАРГА ТАЛӘПЛӘР

5.1.Спорт чарасында теләге булган һәркем катнаша ала.

5.2. 18 яшькә кадәрге гражданнар комиссиягә түбәндәге документларны тапшыралар: шәхесне таныклый торган документ (паспорт яисә туу турында таныклык), белешмә – табибтан рөхсәт (коллектив гариза булуы мөмкин), шулай ук катнашучы карточкасында шәхси имзасын куеп һәм үз баласы өчен шәхси җаваплылыгын, сәламәтлеген раслап ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) ризалыгы, шул исәптән старт урынында медицина тикшерүе оештырылачак.

## 6. КАТНАШУЧЫЛАР ҺӘМ ТАМАШАЧЫЛАР ИМИНЛЕГЕН ТӘЭМИН ИТҮ:

6.1. Спорт ярышларында катнашучыларның һәм тамашачыларның куркынычсызлыгын тәэмин итү спорт корылмасы милекчесе тарафыннан, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 18 апрелендәге 353 номерлы карары белән расланган рәсми спорт ярышларын уздырганда иминлекне тәэмин итү кагыйдәләре таләпләренә ярашлы рәвештә, җиңел атлетика буенча ярышлар кагыйдәләре таләпләренә туры килә.

6.2. Ярышларга медицина хезмәте күрсәтү Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2020 елның 23 октябрендәге 1144н номерлы «Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затларга (шул исәптән физкультура чараларын һәм спорт чараларын әзерләгәндә һәм уздырганда), оешмаларда спорт әзерлеге узарга, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнергә теләгән затларга медицина тикшерүе тәртибен һәм (яисә) «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы сынаулары (тестлары) нормативларын һәм физкультура һәм спорт чараларында катнашуга рөхсәт бирү турында медицина бәяләмәләре

рәвешләрен дә кертеп, медицина ярдәме күрсәтүне оештыру тәртибен раслау турында» боерыгы нигезендә тәэмин ителә.

## 7. КАТНАШУЧЫЛАРНЫ ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ

7.1. Җиңел атлетика йөгерешендә катнашучыларны иминиятләштерү ирекле һәм ярышларда катнашучыларның акчалары исәбеннән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

## 8. ЯРЫШЛАРДА КАТНАШУГА ГАРИЗАЛАР

8.1. Җиңел атлетика ярышларында катнашуга заявкаларны ярышлар уздырылган көнне 09.30 сәгатьтән 10.40 сәгатькә кадәр Әгерже шәһәре, Гагарин урамы, 13 йорт (08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр) 3 нче кабинет, шулай ук LS.Imanova@tatar.ru электрон почтасына, яки судьялар коллегиясенә җибәрергә була.

## 9. БҮЛӘКЛӘҮ

9.1 Һәр яшь төркемендә I-III урыннарны алган катнашучылар медальләр һәм дипломнар белән бүләкләнә.

**Әлеге нигезләмә ярышларга рәсми чакыру булып тора**

«Татарстан кроссы - 2021» массакүләм ярышлар үткәрү турында нигезләмәгә кушымта

18 ЯШЬКӘ КАДӘР КАТНАШУЧЫ КАРТАСЫ

Баланың фамилиясе______________________________________________________

Исеме___________________________________________________________

Атасының исеме_______________________________________________________

Туу датасы______________________________________________________

Әлеге гариза белән ярышлар турындагы Нигезләмә нигезендә үз өстемә баламның сәламәтлеге һәм физик хәле өчен җаваплылык алуымны раслыйм

Ата-анасының Ф.И.Осы, имза

_______________________/______________________/
«____»_______________2021

**Ярышларга үткәрелә / үткәрелми (астына сызарга)**

**Табиб ________________________/________________/**
«____»_______________2021

18 ЯШЬТӘН ӨЛКӘНРӘК КАТНАШУЧЫ КАРТАСЫ

Фамилиясе ____________________________________________________________

Исеме_________________________________________________________________

Атасының
исеме____________________________________________________________

Туу датасы___________________________________________________________

Әлеге гариза белән ярышлар турындагы Нигезләмә нигезендә үземнең сәламәтлегем һәм физик хәлем өчен җаваплылык алуымны раслыйм

Ф.И.О, имза

_________________________/________________________/
«____»________________2021

**Ярышларга үткәрелә / үткәрелми (астына сызарга)**

**Табиб ________________________/_________________/**
«____»________________2021

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
15.09.2021 № 125-р
күрсәтмәсе белән расланган

**«Татарстан кроссы - 2021» массакүләм ярышларын уздыру өчен судьялар составы**

1. Чечегов Сергей Васильевич («Спорт мәктәбе» МБУ) - ярышларнын баш судьясы.
2. Тукаева Гөлназ Рәшид кызы («Спорт мәктәбе» МБУ).
3. Иманова Любовь Сергеевна ( ТР Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге башлыгы)
4. Чуков Илдус Ирек улы («Спорт мәктәбе» МБУ)
5. Семенов Алексей Леонидович ("Спорт мәктәбе" МБУ)
6. Идиятов Илдар Рәмис улы (“Спорт мәктәбе” МБУ)

Татарстан Республикасы
Әгерже муниципаль районы
Башкарма комитетының
15.09.2021 № 125-р
күрсәтмәсе белән расланган

**«Татарстан кроссы - 2021» массакүләм ярышларын үткәрү турында чыгымнарның сметасы**

| Товарлар | Исәбе | Бәясе шт/сум | Бәясе, сум |
|---|---|---|---|
| Медальләр | 50 | 100 | 5000 |
| Грамоталар | 50 | 20 | 1000 |
| Барлыгы | | | 6000 |